ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 21 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Җир кодексының 21 статьясындагы 1 пунктының 5 пунктчасын (2005 елның 18 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 8 (II өлеш); 1999, № 8 (I өлеш); 2005, № 1 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 1 (I өлеш), № 4; 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (III өлеш); 2010, № 11; 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 3, № 5 (I өлеш); 2013, № 1; 2014, № 3) түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) дәүләт яисә муниципаль милектәге җирләрдән – тулысынча федераль бюджет акчалары, Татарстан Республикасы бюджеты акчалары яисә җирле бюджет акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла торган күчемсез мөлкәт объектын төзүгә дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарларны, эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе законнары нигезендә дәүләт яисә муниципаль контракт төзелгән затларга күчемсез мөлкәт объектын төзү вакытына;».

**2 статья**

«Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 25 декабрендәге 1722-XII номерлы Татарстан Республикасы Законының 16 статьясындагы тугызынчы абзацында (1999 елның 6 декабрендәге 2486 номерлы Татарстан Республикасы Законы

редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1992, № 11 – 12; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2000, № 2 (2); 2001, № 12; 2004, № 7 (I өлеш); 2005, № 4 (I өлеш); 2008, № 3; 2009, № 9 – 10; 2012, № 1, № 7 (I өлеш), № 12 (II өлеш); 2014, № 1 – 2) «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар китерүгә, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә заказлар урнаштыру турында» 2005 елның 21 июлендәге 94-ФЗ номерлы» сүзләрен «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарларны, эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы» сүзләренә алмаштырырга.

**3 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 37 статьясындагы 2 өлешен (2005 елның 25 октябрендәге 106-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 1, № 9 (II өлеш); 2005, № 10 (II өлеш); 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2008, № 3, № 10 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 10 (II өлеш); 2011, № 5, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 2 (I өлеш), № 3) түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән дәүләт заказы кысаларында товарларны, эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарларны, эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.».

**4 статья**

«Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» 2008 елның 22 маендагы 22-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2011, № 6 (I өлеш); 2012, № 1, № 12 (I өлеш); 2013, № 12 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяның 3 өлешендәге 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) дәүләт милкендәге җирләрдә урнашкан урманнарны саклау, яклау, торгызу чараларын гамәлгә ашыру федераль башкарма хакимият органнары, Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары буйсынуындагы дәүләт бюджет һәм автономияле учреждениеләргә яисә урманнардан файдаланучы затларга йөкләнмәгән очракларда, дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарларны, эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе законнары нигезендә урманнарны саклау, яклау, торгызу эшләрен сатып алуларны гамәлгә ашыру;»;

2) 8 статьяда «урманнарны саклауга, яклауга һәм торгызуга дәүләт заказын яисә муниципаль заказны бер үк вакытта урман утыртмаларын сату белән урнаштырганда» сүзләрен «урманнарны саклау, яклау, торгызу эшләрен сатып алулар дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашырылганда» сүзләренә алмаштырырга.

**5 статья**

«Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2010 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 1 – 2; 2011, № 10 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2014, № 1 – 2) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяның 3 өлешендә «товарлар кайтартуга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә заказлар урнаштырганда» сүзләрен «товарларны, эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне сатып алуларны гамәлгә ашырганда» сүзләренә алмаштырырга;

2) 22 статьяның 2 пунктында «социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә хезмәт күрсәтүләргә дәүләт заказын урнаштыру» сүзләрен «социаль хезмәт күрсәтүләрне сатып алуларны дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарларны, эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашыру» сүзләренә алмаштырырга.

**6 статья**

«Татарстан Республикасында инновация эшчәнлеге турында» 2010 елның 2 августындагы 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 8 – 9; 2012, № 1) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 17 статьяның 1 өлешендәге 2 пунктында «дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар китереп торуга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә заказлар урнаштыру» сүзләрен «дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарларны, эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар өлкәсендә контракт системасы» сүзләренә алмаштырырга;

2) 17 статьяның 1 өлешендәге 3 пунктында «сатып алуга дәүләт заказы урнаштыру» сүзләрен «сатып алуларны гамәлгә ашыру» сүзләренә алмаштырырга.

**7 статья**

«Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының

14 статьясындагы 3 өлешендә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 12 (II өлеш); 2011 № 10 (I өлеш); 2012, № 3) «дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар китереп торуга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә заказлар урнаштыру» сүзләрен «дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарларны, эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар өлкәсендә контракт системасы» сүзләренә алмаштырырга.

**8 статья**

«2011 – 2015 елларга Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү программасын раслау турында» 2011 елның 22 апрелендәге 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы кушымтасының 3 бүлегендәге 3.5 бүлекчәсенең 3.5.2 пунктындагы уникенче абзацында (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 4 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2014, № 1 – 2) «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар китерүгә, эшләр башкаруга һәм хезмәтләр күрсәтүгә заказлар урнаштыру турында» 2005 елның 21 июлендәге 94-ФЗ номерлы» сүзләрен «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарларны, эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы» сүзләренә алмаштырырга.

**9 статья**

«Татарстан Республикасында янгыннан ирекле саклау турында» 2011 елның 1 августындагы 48-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 9 статьясындагы 3 пунктын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 8 (I өлеш) түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарларны, эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы» Федераль законда каралган тәртиптә янгыннан саклауның иҗтимагый берләшмәләреннән дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарларны, эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне сатып алуларны гамәлгә ашыру;».

**10 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен мәҗбүри дәүләт иминләштерүе турында» 2012 елның 14 июлендәге 55-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы 3 өлешендә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 7 (I өлеш) «дәүләт ихтыяҗлары өчен товарлар ташуга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә заказлар урнаштыру» сүзләрен «дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарларны, эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар өлкәсендә контракт системасы» сүзләренә алмаштырырга.

**11 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2014 елның 14 мае
№ 32-ТРЗ